**ХАЛЫК ЖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 10** **22.11.2024 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Урсай авыл җирлеге составына керүче
Урсай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «2024 елның 22 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

« Сез 2025 елда Урсай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм анда катнашучыларның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, махсус хәрби операциягә җибәрелгән мобилизацияләнүчеләрнең гаилә әгъзаларыннан тыш, бер тапкыр бирелә торган түләүне киметергә 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә билгеләп, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алмаштыру, Урсай авылы урамнарын яктыртуны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү хезмәтләре күрсәтү);
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Урсай авылы торбаларын алыштыру,килешү буенча эшләр өчен түләү, материаллар, җайланмалар сатып алу, авария хәлләрен бетерү,);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Урсай торак пунктында юлларны профильләштерү);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (Урсай авылының Совет урамы буенча (мафлар сатып алу һәм урнаштыру, койма сатып алу һәм урнаштыру , Урсай авылының юлларын кардан чистарту).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 477 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны – 376 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 376 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Үрсай авыл җирлеге составына керүче Урсай авылыдна узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.
2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: Сез 2025 елда үзара салым кертүгә килешәсезме Урсай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм анда

катнашучыларның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, гаилә әгъзаларының мобилизацияләнгән гаилә әгъзаларыннан махсус хәрби операциягә җибәрелгән бер тапкыр бирелә торган түләүне киметеп, 400 сум күләмендә һәм 2 группа инвалидлар өчен 200 сум күләмендә алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алмаштыру, Урсай авылы урамнарын яктыртуны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү хезмәтләре күрсәтү);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Урсай авылы торбаларын алыштыру,килешү буенча эшләр өчен түләү, материаллар, җайланмалар сатып алу, авария хәлләрен бетерү,);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Урсай торак пунктында юлларны профильләштерү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Урсай авылының Совет урамы буенча (мафлар сатып алу һәм урнаштыру, койма сатып алу һәм урнаштыру , Урсай авылының юлларын кардан чистарту).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Урсай авылы, Үзәк урамы, 60 йорт;

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Урсай авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урсай авыл җирлеге Башлыгы З.Х.Рахимьянова